**ГЛАВА**
**Кулегашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Күләгәш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.10.2022 № 1 Күләгәш авылы

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. 2022 елның 28 октябрендә 11 сәгать 00 минутка, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2022 елның 28 октябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә:

-1 этап: Күләгәш авылының Яшьләр урамында, Лесная урамында, Казан урамында яшәүчеләр.

-2 этап: Күләгәш авылының Совет урамында, Спорт тыкрыгында яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: «2023 елда Күләгәш авыл җирлегенең Күләгәш торак пункты территориясендә яшәү

урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, студентлардан, көндезге формада белем алучы затлардан, Россия армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, 300 сум күләмендә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, үзара салым чараларын кертүгә сез риза булырсызмы?»:

- янгын сүндерү машинасын тоту, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт шартнамәсе буенча түләү;

- үләнне чаптыру (хезмәт шартнамәсе буенча түләү);

- МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, юлларга хезмәт күрсәтү, кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу, запчастьләр, хезмәт килешүе буенча түләү);

- Бөек Ватан сугышы елларында катнашучы якташлар хөрмәтенә куелган һәйкәлне агымдагы елда ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәт шартнамәсе буенча түләү);

- Күләгәш авылының Яшьләр, Казан урамнары, Спорт тыкрыгы юллары өчен вак таш алу һәм аларны каплау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Күләгәш ав., Совет ур., 38 А йорты, авыл мәдәният йорты.

6. Күләгәш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Ю.Н.ВАСИЛЬЕВ

Совет Кулегашского сельского поселения
Күләгәш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002639